**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2023 елның «11» апреленнән № 109

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 апрелендәге 203 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында өч һәм аннан күбрәк савым сыеры булган, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга саву аппараты сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 апрелендәге 203 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында өч һәм аннан күбрәк савым сыеры булган, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга саву аппараты сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 өлешнең 1.4. пунктындагы беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталындагы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru гаризалар сайлап алуны үткәрү турында мәгълүмат (алга таба - сайлап алуны үткәрү турында

игълан) урнаштыра:»;

1.2. 1 өлешнең 1.4. пунктындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (гаризаларын) кабул итә башлау яисә тәмамлау даталары, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 календарь көненнән дә алдарак була алмый;»;

1.3. 2.6. пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«Субсидияләр бирү түбәндәгеләр нигезендә башкарыла:

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы тарафыннан расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында өч һәм аннан күбрәк савым сыеры булган, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга саву аппараты сатып алуга бәйле чараларны гамәлгә ашыру максатларында шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнар белән төзелгән ике яклы килешү;

Комиссия карары нигезендә бюджет чараларын баш бүлүченең - башкарма комитетның - шәхси счетыннан акчаларны күчерү юлы белән әзерләнгән җыелма белешмә-хисаплар - гражданнарның гаризада һәм җыелма белешмә-хисапларда күрсәтелгән шәхси счетларына.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru , «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http// novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча) йөкләргә.

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ИНН 1631003397 ОГРН 1051660041740

Җитәкче Р.Р. Фасахов